КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 29 сентябрь г.Казань № 1049

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Закон территориясе» еллык республика конкурсын үткәрү турында» 2012 ел, 20 февраль, 135 нче карары белән расланган «Закон территориясе» еллык республика конкурсын үткәрү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Закон территориясе» еллык республика конкурсын үткәрү турында» 2012 ел, 20 февраль, 135 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 29 май, 454 нче; 2019 ел, 23 ноябрь, 1073 нче; 2021 ел, 12 февраль, 75 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Закон территориясе» еллык республика конкурсын үткәрү турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктта «шулай ук хосусый саклау оешмалары, хокук саклау юнәлешендәге иҗтимагый берләшмәләр җитәкчеләре» сүзләрен «хосусый саклау оешмалары, хокук саклау юнәлешендәге иҗтимагый берләшмәләр җитәкчеләре, шулай ук балигъ булмаганнарның җәмәгатьчелек тәрбиячеләре» сүзләренә алмаштырырга;

3.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«ж) балигъ булмаганнарның җәмәгатьчелек тәрбиячеләре.»;

4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Конкурс түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

«Авыл җирлеге территориясендә хокук тәртибен тәэмин итүгә өлеш керткән өчен» (әлеге номинациядә авыл җирлекләре башлыклары бүләкләнә);

«Муниципаль район һәм шәһәр округы территориясендә хокук тәртибен тәэмин итүгә өлеш керткән өчен» (әлеге номинациядә муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары башлыклары һәм (яки) җитәкчеләре бүләкләнә);

«Хокук саклау эшчәнлегенә булышлык күрсәтүгә өлеш керткән өчен» (әлеге номинациядә оешмалар җитәкчеләре бүләкләнә);

«Мәгариф оешмаларының белем алучылары арасында хокук бозуларны профилактикалауга өлеш керткән өчен» (әлеге номинациядә мәгариф оешмалары җитәкчеләре бүләкләнә);

«Үсеп килүче буынны тәрбияләүгә, яшьләрдә һәм яшүсмерләрдә җәмгыятьнең хокукый нигезләренә карата хөрмәт формалаштыруга өлеш керткән өчен» (әлеге номинациядә мәгариф оешмалары, спорт һәм мәдәният үзәкләре, яшүсмерләр һәм яшьләр белән эшли торган клублар җитәкчеләре һәм (яки) хезмәткәрләре бүләкләнә);

«Хосусый саклау оешмаларын җәлеп итеп, иҗтимагый тәртипне саклауга өлеш керткән өчен» (әлеге номинациядә хосусый саклау оешмаларын гамәлгә куючылар һәм (яки) аларның җитәкчеләре, лицензия таләпләре буенча ачыкланган бозулары булган, аларны берничә тапкыр һәм (яки) тупас бозган хосусый саклау оешмаларына конкурста катнашырга рөхсәт ителми);

«Җәмәгатьчелекне җәлеп итеп, иҗтимагый тәртипне саклауга өлеш керткән өчен» (әлеге номинациядә хокук саклау юнәлешендәге иҗтимагый берләшмәләрне гамәлгә куючылар һәм (яки) аларның әгъзалары бүләкләнә);

«Балигъ булмаганнарны иҗтимагый тәрбияләүгә өлеш керткән өчен».»;

5.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Конкурс ике этапта үткәрелә:

1 нче этап – республиканың муниципаль районнарында һәм шәһәр округларында түбәндәге номинацияләр буенча:

«Авыл җирлеге территориясендә хокук тәртибен тәэмин итүгә өлеш керткән өчен»;

«Хокук саклау эшчәнлегенә булышлык күрсәтүгә өлеш керткән өчен»;

«Мәгариф оешмаларының белем алучылары арасында хокук бозуларны профилактикалауга өлеш керткән өчен»;

«Үсеп килүче буынны тәрбияләүгә, яшьләрдә һәм яшүсмерләрдә җәмгыятьнең хокукый нигезләренә карата хөрмәт формалаштыруга өлеш керткән өчен»;

«Хосусый саклау оешмаларын җәлеп итеп, иҗтимагый тәртипне саклауга өлеш керткән өчен»;

«Җәмәгатьчелекне җәлеп итеп, иҗтимагый тәртипне саклауга өлеш керткән өчен»;

«Балигъ булмаганнарны иҗтимагый тәрбияләүгә өлеш керткән өчен»;

2 нче этап Казан шәһәрендә 1 нче этапның җиңүчеләре арасында үткәрелә.

«Муниципаль район һәм шәһәр округы территориясендә хокук тәртибен тәэмин итүгә өлеш керткән өчен» номинациясе буенча конкурс бер этапта үткәрелә.»;

5.5 пунктта «7» санын «8» санына алмаштырырга;

әлеге Тәртипкә 8 нче кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

«Закон территориясе» еллык
республика конкурсын үткәрү
турындагы нигезләмәгә
8 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 29 сентябрь, 1049 нчы
карары редакциясендә)

«Балигъ булмаганнарны иҗтимагый тәрбияләүгә өлеш керткән өчен» номинациясендә материалларны бәяләү критерийлары

| Т/с | Критерий исеме | Баллар саны |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Опекага алынган, балигъ булмаган зат белән профилактик эшнең индивидуаль планы булу: аның нигезлелеге (балигъ булмаган затның яшен, аның мәнфәгатьләрен исәпкә алу), актуальлеге, план чараларын тормышка ашыруның конкретлыгы, планның инновацион-иҗади характеры | + 1<br>(балигъ булмаган затның шәхес үзенчәлекләрен исәпкә алып, тормышка ашырылган һәр чара өчен) |
| 2. | Балигъ булмаган зат белән профилактик эш алып барганда ведомствоара хезмәттәшлек, профилактика системасы органнары белән бергәләп эшләү нәтиҗәлелеге | + 1<br>(бергәләп үткәрелә торган чарада һәр катнашу өчен) |
| 3. | Балигъ булмаган затка белем алуда ярдәм күрсәтү | +10 |
| 4. | Балигъ булмаган затка эшкә, шул исәптән вакытлыча эшкә урнашуда булышлык күрсәтү | +10 |
| 5. | Балигъ булмаган затны тәрбияләүдә ата-аналарга ярдәм күрсәтү | +10 |
| 6. | Балигъ булмаган затның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау буенча чараларны гамәлгә ашыру | +10 |
| 7. | Балигъ булмаган затның спорт һәм мәдәният чараларында катнашуы | +1<br>(һәр чара өчен) |
| 8. | Опекага алынган, балигъ булмаган затны спорт секцияләренә, иҗади түгәрәкләргә, өстәмә белем бирү дәресләренә җәлеп итү | +10 |
| 9. | Опекага алынган, балигъ булмаган затны хоббига җәлеп итү | +10 |
| 10. | Балигъ булмаган затның җәйге ялын оештыруда булышлык күрсәтү | +10 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 11. | Балигъ булмаган затны патриотик юнәлештәге чараларга җәлеп итү | +10 |
| 12. | Үткәрелә торган профилактик эшнең нәтиҗәлелеген раслый торган материаллар булу | +10 |